КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ПО ОХРАНЕ ОБЪЕКТОВ
КУЛЬТУРНОГО НАСЛЕДИЯ

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ МӘДӘНИ
МИРАС ОБЪЕКТЛАРЫН
САКЛАУ КОМИТЕТЫ

**ПРИКАЗ БОЕРЫК**

09.02.2026 № 60-П

Казан ш.

Федераль әһәмияттәге мәдәни мирас объектларының (федераль әһәмияттәге аерым мәдәни мирас объектлары исемлегенә кертелгән федераль әһәмияттәге мәдәни мирас объектларыннан тыш), региональ әһәмияттәге мәдәни мирас объектларының мәгълүмат язулары һәм билгеләре проектларын карау һәм килештерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Республика башкарма хакимияте органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларын көчен югалткан дип тану турында» 2022 елның 28 февралендәге 175 номерлы карары нигезендә боерык бирәм:

1. Кушымтада бирелә торган Федераль әһәмияттәге мәдәни мирас объектларының (федераль әһәмияттәге аерым мәдәни мирас объектлары исемлегенә кертелгән федераль әһәмияттәге мәдәни мирас объектларыннан тыш), региональ әһәмияттәге мәдәни мирас объектларының мәгълүмат язулары һәм билгеләре проектларын карау һәм килештерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын (алга таба – Регламент) расларга.

2. Түбәндәгеләрне гамәлдән чыккан дип танырга:

Татарстан Республикасы Мәдәни мирас объектларын саклау комитетының «Федераль әһәмияттәге мәдәни мирас объектларының (федераль әһәмияттәге аерым мәдәни мирас объектлары исемлегенә кертелгән федераль әһәмияттәге мәдәни мирас объектларыннан тыш), региональ әһәмияттәге мәдәни мирас объектларының мәгълүмат язулары һәм билгеләре проектларын карау һәм килештерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2022 елның 10 ноябрендәге 425-П номерлы боерыгын;

Татарстан Республикасы Мәдәни мирас объектларын саклау комитетының «Татарстан Республикасы Мәдәни мирас объектларын саклау комитетының

«Федераль әһәмияттәге мәдәни мирас объектларының (федераль әһәмияттәге аерым мәдәни мирас объектлары исемлегенә кертелгән федераль әһәмияттәге мәдәни мирас объектларыннан тыш), региональ әһәмияттәге мәдәни мирас объектларының мәгълүмат язулары һәм билгеләре проектларын карау һәм килештерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2022 елның 10 ноябрендәге 425-П номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү хакында» 2024 елның 19 августындагы 420-п номерлы боерыгын.

3. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

Рәис И.Н.Гущин

Татарстан Республикасы
Мәдәни мирас объектларын
саклау комитетының 2026 елның
09 февралендәге 60-П номерлы
боерыгы белән расланды

# Федераль әһәмияттәге мәдәни мирас объектларының (федераль әһәмияттәге аерым мәдәни мирас объектлары исемлегенә кертелгән федераль әһәмияттәге мәдәни мирас объектларыннан тыш), региональ әһәмияттәге мәдәни мирас объектларының мәгълүмат язулары һәм билгеләре проектларын карау һәм килештерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Федераль әһәмияттәге мәдәни мирас объектларының (федераль әһәмияттәге аерым мәдәни мирас объектлары исемлегенә кертелгән федераль әһәмияттәге мәдәни мирас объектларыннан тыш), региональ әһәмияттәге мәдәни мирас объектларының мәгълүмат язулары һәм билгеләре проектларын карау һәм килештерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты (алга таба – Регламент) дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфатын һәм аннан һәркем файдалана алырлык булу дәрәҗәсен арттыру максатларында эшләнде, федераль әһәмияттәге мәдәни мирас объектларының (федераль әһәмияттәге аерым мәдәни мирас объектлары исемлегенә кертелгән федераль әһәмияттәге мәдәни мирас объектларыннан тыш), региональ әһәмияттәге мәдәни мирас объектларының мәгълүмат язулары һәм билгеләре проектларын карау һәм килештерү буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашырганда гамәлләрнең (алга таба – дәүләт хезмәте) стандартын, вакытларын һәм эзлеклелеген билгели.

1.2. Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларының (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләренең) бердәм дәүләт реестрына кертелгән мәдәни мирас объектына милек хокукында ия булган физик яисә юридик затлар мөрәҗәгать итүчеләр (алга таба – мөрәҗәгать итүче) булып торалар, шул исәптән «Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре) турында» 2002 елның 25 июнендәге 73-ФЗ номерлы федераль законның $47^6$ статьясындагы 11 пункты нигезендә әлеге объект гражданлык хокукы шартнамәсе нигезендә өченче зат (өченче затлар) милкендә яисә файдалануында булган очракта да.

Мөрәҗәгать итүчеләр исеменнән законнарда билгеләнгән тәртиптә бирелгән ышанычнамә нигезендә эш итүче затлар (мөрәҗәгать итүченең вәкиле) эш итә ала.

1.3. Дәүләт хезмәте мөрәҗәгать итүчегә мөрәҗәгать итүчеләрнең категорияләре (билгеләре) нигезендә күрсәтелә, алар турында белешмәләр «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасында (http://www.gosuslugi.ru/) (алга таба – Бердәм портал), «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы» дәүләт мәгълүмат системасында (http://uslugi.tatarstan.ru/) (алга таба – Республика

порталы) һәм «Дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең (функцияләрнең) федераль реестры» федераль дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырыла.

Бердәм порталда мөрәҗәгать итүченең (мөрәҗәгать итүче вәкиленең) Төбәк порталындагы шәхси кабинетында дәүләт хезмәте күрсәтү барышы турында статуслар урнаштырыла һәм дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе, мөрәҗәгать итүченең (мөрәҗәгать итүче вәкиленең) дәүләт хезмәте күрсәтүне сорап мөрәҗәгать итү ысулына бәйсез рәвештә, урнаштырыла.

1.4. Кулланыла торган билгеләр һәм кыскартулар исемлеге шушы Регламентның 1 нче кушымтасында китерелгән.

## 2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

2.1. Күрсәтелә торган дәүләт хезмәте атамасы

Федераль әһәмияттәге мәдәни мирас объектларының (федераль әһәмияттәге аерым мәдәни мирас объектлары исемлегенә кертелгән федераль әһәмияттәге мәдәни мирас объектларыннан тыш), региональ әһәмияттәге мәдәни мирас объектларының мәгълүмат язулары һәм билгеләре проектларын карау һәм килештерү.

2.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүче органның исеме

Татарстан Республикасы Мәдәни мирас объектларын саклау комитеты (алга таба – Комитет).

Дәүләт хезмәтен башкаручы – Комитетның мәдәни мирас объектларын саклау бүлеге (алга таба – бүлек).

2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе

2.3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булып түбәндәгеләр тора:

федераль әһәмияттәге мәдәни мирас объектының (федераль әһәмияттәге аерым мәдәни мирас объектлары исемлегенә кертелгән федераль әһәмияттәге мәдәни мирас объектыннан тыш), региональ әһәмияттәге мәдәни мирас объектының мәгълүмат язуы һәм билгесе проектын карау һәм килештерү турында карар (әлеге Регламентның 6 нчы кушымтасында китерелгән форма буенча) (алга таба – килештерү турында карар);

федераль әһәмияттәге мәдәни мирас объектының (федераль әһәмияттәге аерым мәдәни мирас объектлары исемлегенә кертелгән федераль әһәмияттәге мәдәни мирас объектыннан тыш), региональ әһәмияттәге мәдәни мирас объектының мәгълүмат язуы һәм билгесе проектын карау һәм килештерүдән баш тарту турында карар (әлеге Регламентның 7 нче кушымтасында китерелгән форма буенча) (алга таба – килештерүдән баш тарту турында карар).

Дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсе Комитет бланкында рәсмиләштерелә, билгеләнгән тәртиптә кабул ителә.

Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча мәгълүмат системасында реестр язуын теркәү зарурлыгы юк.

2.3.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе аны алу буенча сайланган ысул белән мөрәҗәгать итүчегә бирелә (җибәрелә):

язмача формада мөрәҗәгать итүчегә шәхсән яисә почта аша;

электрон документ формасында электрон почта адресы буенча яки Республика порталында мөрәҗәгать итүченең шәхси кабинетына.

2.3.3. Мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен кәгазь документ нөсхәсе рәвешендә алырга хокуклы.

Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен кәгазь чыганакта алу өчен мөрәҗәгать итүче Комитетка мөрәҗәгать итә.

2.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтү вакыты

2.4.1. Дәүләт хезмәтен күрсәтү турындагы гариза (алга таба – гариза) һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан почта, электрон почта аша яисә шәхсән тапшырылган очракта, Комитет тарафыннан дәүләт хезмәтен күрсәтүнең максималь вакыты – гариза һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документлар теркәлгән көннән алып 30 календарь көн.

2.4.2. Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле гариза һәм документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан Республика порталында мөрәҗәгать итүченең шәхси кабинеты аша тапшырылган очракта, Комитет тарафыннан дәүләт хезмәтен күрсәтүнең максималь вакыты – Республика порталының шәхси кабинетында чагылдырылган эшләр номенклатурасы һәм «Документларны тикшерү» статусы нигезендә гаризага номер бирелгән көннән алып 30 календарь көн.

2.5. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә мөрәҗәгать итүчедән алына торган түләү күләме һәм аны алу ысуллары

Дәүләт хезмәте түләүсез нигездә күрсәтелә.

2.6. Гариза биргәндә һәм мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәсен алганда чират көтүнең максималь вакыты

Гариза биргәндә һәм мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәсен алганда чират көтүнең максималь вакыты 15 минуттан артмаска тиеш.

Мөрәҗәгать итүчеләрнең аерым категорияләре өчен чират билгеләнмәгән.

2.7. Мөрәҗәгать итүченең гаризасын теркәү вакыты

2.7.1. Комитетка шәхсән мөрәҗәгать иткәндә, теркәү гариза һәм документлар кергән көнне башкарыла. Ял (бәйрәм) көнендә электрон рәвештә килгән гариза ял (бәйрәм) көненнән соңгы эш көнендә теркәлә.

2.7.2. Гаризаны Республика порталы аша җибәргән очракта, мөрәҗәгать итүче гариза биргән көнне Республика порталындагы шәхси кабинетта һәм электрон почта буенча гаризаның җибәрелгән булуын раслый торган белдерү ала, анда гаризаның теркәлү номеры һәм тапшырылу датасы күрсәтелә.

2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган бүлмәләргә карата таләпләр

Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналар туры килергә тиешле таләпләр Комитетның рәсми сайтында, шулай ук Республика порталында урнаштырылган.

2.9. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең мөмкинлекле һәм сыйфатлы булу күрсәткечләре

Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналар туры килергә тиешле таләпләр Комитетның рәсми сайтында, шулай ук Республика порталында урнаштырылган.

2.10. Дәүләт хезмәте күрсәтүгә башка таләпләр, шул исәптән:

дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләрендә (алга таба – КФҮ) дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләрен һәм электрон рәвештә дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә ала торган;

Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә дәүләт хезмәте турында белешмәләр бирү турында.

2.10.1. Зарури һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми.

2.10.2. Консультация мөрәҗәгать итүче Бүлеккә шәхсән, телефон, электрон почта, почта аша мөрәҗәгать иткәндә бирелергә мөмкин.

2.10.3. Дәүләт хезмәте КФҮ аша күрсәтелми.

2.10.4. Электрон формада дәүләт хезмәте күрсәткәндә мөрәҗәгать итүче хокуклы:

дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында Республика порталында урнаштырылган мәгълүматны алырга;

гаризаны, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле башка документларны, шул исәптән электрон үрнәкләре элегрәк «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль законның (алга таба – 210-ФЗ номерлы федераль закон) 16 статьясының 1 өлешендәге $7^2$ пункты нигезендә танылганган документларны һәм мәгълүматны Республика порталыннан файдаланып тапшырырга;

электрон рәвештә бирелгән гаризаны үтәү барышы турында белешмәләр алырга;

дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфатына бәя бирергә;

дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен электрон документ формасында алырга;

дәүләт хезмәтләре күрсәтә торган органнар, аларның вазыйфаи затлары тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә кабул ителгән карарларга һәм кылынган гамәлләргә (гамәл кылмауга) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү процессын тәэмин итә торган Республикасы порталы ярдәмендә Комитет, шулай ук аның вазыйфаи затлары, дәүләт хезмәткәрләре карарына һәм гамәленә (гамәл кылмавына) шикаять бирергә.

Гаризаны формалаштыру, гаризаны өстәмә рәвештә нинди дә булса башка формада тапшыру зарурлыгыннан тыш, Республика порталында гаризаның электрон формасын тутыру юлы белән гамәлгә ашырыла.

2.10.5. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә «Ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең бердәм системасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасы кулланыла.

2.10.6. Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында мәгълүмат Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә урнаштырыла.

2.10.7. Экстерриториаль принцип буенча һәм комплекслы мөрәҗәгать составында дәүләт хезмәте күрсәтелми.

2.11. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның тулы исемлеге

Әлеге Регламентның 3 нче кушымтасы таблицасында дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларның тулы исемлеге китерелгән, түбәндәгечә бүленешләр белән:

мөрәҗәгать итүче үзе тапшырырга тиешле документлар;

ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында тапшырылырга тиешле, мөрәҗәгать итүче үз инициативасы белән тапшырырга хокуклы булган документлар.

Гариза формалары һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар турында белешмәләр шушы Регламентның 5 нче кушымтасында китерелгән.

Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек гамәлгә ашырылмый.

2.12. Дәүләт хезмәтен күрсәтү турында гаризаны һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге һәм дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге

2.12.1. Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге шушы Регламентның 4 нче кушымтасында китерелгән.

Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза рәвешендә мәҗбүри кырларны дөрес тутырмау (төгәл түгел, дөрес түгел яисә тулысынча тутырмау);

тапшырылган документларның дәүләт хезмәте күрсәтүне сорап мөрәҗәгать итү вакытына көчен югалтуы (шәхесне таныклый торган документ, мөрәҗәгать итүче вәкиленең вәкаләтләрен таныклый торган документ, – дәүләт хезмәте күрсәтүне сорап әлеге зат мөрәҗәгать иткән очракта);

мөрәҗәгать итүче тарафыннан кәгазьдә тапшырылган документларда Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган чистартылган һәм текстны төзәткән урыннар булуы;

электрон рәвештә тапшырылган документларда дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларда булган мәгълүматны һәм белешмәләрне тулы күләмендә файдалану мөмкинлеген бирми торган бозык урыннар булуы;

электрон рәвештәге гариза һәм башка документлар электрон имза белән «Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы федераль закон таләпләрен бозып имзаланган.

2.12.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге

Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр законнарда каралмаган.

Дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге шушы Регламентның 4 нче кушымтасында китерелгән.

Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләре:

мәдәни мирас объектындагы мәгълүмат язуы проекты эчтәлегенең Россия Федерациясе халыклары мәдәни мирас объектларының (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләренең) бердәм дәүләт реестрындагы белешмәләргә туры килмәве;

проектның Россия Федерациясе халыклары мәдәни мирас объектларындагы (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләрендәге) мәгълүмат язулары һәм билгеләр эчтәлегенә һәм мондый урнаштыру гамәлгә ашырыла торган мәгълүмат язулары һәм билгеләрен

урнаштыру һәм аларның эчтәлеге проектлары составына карата Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе халыклары мәдәни мирас объектларына (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләренә) мәгълүмат язулары һәм билгеләр урнаштыру кагыйдәләрен, әлеге мәгълүмати язуларының һәм билгеләренең эчтәлеген, шулай ук мондый урнаштыру гамәлгә ашырыла торган мәгълүмат язулары һәм билгеләрен урнаштыру һәм аларның эчтәлеге проектлары составына таләпләрне раслау турында» 2019 елның 10 сентябрендәге 1178 номерлы карары белән расланган таләпләргә туры килмәве;

мәдәни мирас объектының Комитет тарафыннан расланган сак предметына туры килмәве.

2.12.4. Гариза дәүләт хезмәтен күрсәтү сроклары һәм тәртибе турында Республика порталында, Комитетның рәсми сайтында бастырып чыгарылган мәгълүмат нигезендә бирелгән очракта, дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту тыела.

2.12.5. Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарткан очракта, Комитет мөрәҗәгать итүчегә мондый баш тартуның сәбәпләре турында, кире кагуга сәбәп булган документлар һәм мәгълүмат исемлеген күрсәтеп, шулай ук федераль законнарда һәм (яисә) башка норматив хокукый актларда билгеләнгән дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартуга китергән таләпләр исемлеген күрсәтеп, хәбәр итә.

## 3. Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм үтәлү сроклары.

3.1. Мөрәҗәгать итүче һәм (яисә) мөрәҗәгать итүченең объектлары һәм (яисә) башка объектлар турында белешмәләрне, шулай ук мөрәҗәгать итүченең белемнәрен (күнекмәләрен) аларның Россия Федерациясе законнары таләпләренә туры килү-килмәвен бәяләү (дәүләт хезмәте күрсәтү (күрсәтүдән баш тарту) турында карар кабул итү процедурасы кысаларында тикшерелә торган таләпләрдән тыш) үткәрелә торган административ процедураны, дәүләт хезмәте күрсәтү турында карар кабул ителгәннән соң мөрәҗәгать итүчегә карата чикләнгән ресурсны (шул исәптән җир кишәрлекләрен, радиоешлыкларны, квоталарны) бүлүне күздә тоткан административ процедураны, мөрәҗәгать итүчедән өстәмә белешмәләр алуның административ процедурасын, бер дәүләт хезмәте күрсәтү кысаларында ике һәм аннан күбрәк мәртәбә кабатлау рөхсәт ителә торган дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып торуның административ процедурасын гамәлгә ашыру каралмаган.

Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә гамәлгә ашырыла торган административ процедуралар исемлеге:

мөрәҗәгать итүчене профильләштерү;

гаризаны, дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документлар һәм (яисә) мәгълүматны кабул итү;

дәүләт хезмәте күрсәтү турында (күрсәтүдән баш тарту турында) карар кабул итү;

дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү.

3.2. Дәүләт хезмәте алгарышлы (проактив) режимда күрсәтелми.

## 4. Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаны карау статусын үзгәртү турында мөрәҗәгать итүчегә хәбәр итү ысуллары

4.1. Бердәм порталда мөрәҗәгать итүченең (мөрәҗәгать итүче вәкиленең) Республика порталындагы шәхси кабинетында дәүләт хезмәте күрсәтү барышы турында статуслар урнаштырыла һәм дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе, мөрәҗәгать итүченең (мөрәҗәгать итүче вәкиленең) дәүләт хезмәте күрсәтүне сорап мөрәҗәгать итү ысулына бәйсез рәвештә, урнаштырыла.

Федераль әһәмияттәге мәдәни мирас объектларының (федераль әһәмияттәге аерым мәдәни мирас объектлары исемлегенә кертелгән федераль әһәмияттәге мәдәни мирас объектларыннан тыш), региональ әһәмияттәге мәдәни мирас объектларының мәгълүмат язулары һәм билгеләре проектларын карау һәм килештерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 1 нче кушымта

Кулланыла торган кыскартулар исемлеге

Гариза – дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза;

Дәүләт хезмәте – федераль әһәмияттәге мәдәни мирас объектларының (федераль әһәмияттәге аерым мәдәни мирас объектлары исемлегенә кертелгән федераль әһәмияттәге мәдәни мирас объектларыннан тыш), региональ әһәмияттәге мәдәни мирас объектларының мәгълүмат язулары һәм билгеләре проектларын карау һәм килештерү буенча дәүләт хезмәте;

Комитет – Татарстан Республикасы Мәдәни мирас объектларын саклау комитеты;

КФҮ – дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләре;

Бүлек – Татарстан Республикасы Мәдәни мирас объектларын саклау комитетының мәдәни мирас объектларын саклау бүлеге;

Мөрәҗәгать итүченең вәкиле – мөрәҗәгать итүченең мәнфәгатьләрен тәкъдим итү буенча тиешле вәкаләтләргә ия затлар;

Хат проекты – дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе проекты;

Регламент – Федераль әһәмияттәге мәдәни мирас объектларының (федераль әһәмияттәге аерым мәдәни мирас объектлары исемлегенә кертелгән федераль әһәмияттәге мәдәни мирас объектларыннан тыш), региональ әһәмияттәге мәдәни мирас объектларының мәгълүмат язулары һәм билгеләре проектларын карау һәм килештерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты;

килештерү турында карар – Федераль әһәмияттәге мәдәни мирас объектының (федераль әһәмияттәге аерым мәдәни мирас объектлары исемлегенә кертелгән федераль әһәмияттәге мәдәни мирас объектыннан тыш), региональ әһәмияттәге мәдәни мирас объектының мәгълүмат язуы һәм билгесе проектын килештерү турында карар;

килештерүдән баш тарту турында карар – Федераль әһәмияттәге мәдәни мирас объектының (федераль әһәмияттәге аерым мәдәни мирас объектлары исемлегенә кертелгән федераль әһәмияттәге мәдәни мирас объектыннан тыш), региональ әһәмияттәге мәдәни мирас объектының мәгълүмат язуы һәм билгесе проектын килештерүдән баш тарту турында карар;

Республика порталы – Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы ((https://uslugi.tatarsta№.ru/);

210-ФЗ номерлы федераль закон – «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль закон;

63-ФЗ номерлы федераль закон – «Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы федераль закон;

Электрон документлар әйләнеше – Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының «Электрон Хөкүмәт» бердәм ведомствоара электрон документлар әйләнеше системасы.

Федераль әһәмияттәге мәдәни мирас объектларының (федераль әһәмияттәге аерым мәдәни мирас объектлары исемлегенә кертелгән федераль әһәмияттәге мәдәни мирас объектларыннан тыш), региональ әһәмияттәге мәдәни мирас объектларының мәгълүмат язулары һәм билгеләре проектларын карау һәм килештерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 2 нче кушымта

## Мөрәҗәгать итүчеләрнең категорияләре (билгеләре) идентификаторлары

| № | Хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе | Мөрәҗәгать итүченең аерым билгесе исеме | Мөрәҗәгать итүчеләрнең аерым билгесе идентификаторы |
|---|---|---|---|
| 1 | Мәдәни мирас объектының мәгълүмат язуы һәм билгесе проектын килештерү/ килештерүдән баш тарту турында карар | Шәхси эшкуарны да кертеп, физик зат | 1А |
| 2 | | Физик зат исеменнән, шәхси эшкуарны да кертеп, ышанычнамә нигезендә эш итүче зат | 2А |
| 3 | | Юридик зат исеменнән ышанычнамәсез эш итәргә хокуклы зат | 3А |
| 4 | | Юридик зат исеменнән эш итүче зат ышанычнамә нигезендә | 4А |

Федераль әһәмияттәге мәдәни мирас объектларының (федераль әһәмияттәге аерым мәдәни мирас объектлары исемлегенә кертелгән федераль әһәмияттәге мәдәни мирас объектларыннан тыш), региональ әһәмияттәге мәдәни мирас объектларының мәгълүмат язулары һәм билгеләре проектларын карау һәм килештерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 3 нче кушымта

Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның тулы исемлеге

| № | Идентификатор | Мөрәҗәгать итүче тапшыра торган документлар төрләрен, төркемнән документлар санын расшифровкалау |
|---|---|---|
| *Мөрәҗәгать итүче үзе тапшырырга тиешле документлар* | | |
| 1. | 1А-4А | Федераль әһәмияттәге мәдәни мирас объектының (федераль әһәмияттәге аерым мәдәни мирас объектлары исемлегенә кертелгән федераль әһәмияттәге мәдәни мирас объектыннан тыш), региональ әһәмияттәге мәдәни мирас объектының мәгълүмат язуы һәм билгесе проектын карау һәм килештерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза |
| 2. | 1А-4А | Мөрәҗәгать итүченең яисә мөрәҗәгать итүче вәкиленең шәхесен таныклаучы документ |
| 3 | 1А-4А | «Россия Федерациясе халыклары мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләре) турында» 2002 елның 25 июнендәге 73-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә билгеләнә торган тәртиптә әзерләнгән мәдәни мирас объектының мәгълүмат язуы һәм билгесе проекты |
| 4 | 4А | Ышаныч кәгазе |
| 5 | 2А, 3А | Мөрәҗәгать итүче вәкиленең мөрәҗәгать итүче исеменнән эш итү вәкаләтләрен раслый торган документ |
| *Ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында тапшырылырга тиешле, мөрәҗәгать итүче үз инициативасы белән тапшырырга хокуклы булган документлар* | | |
| | Мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен үзе тапшырырга хокуклы документлар каралмаган | |

Федераль әһәмияттәге мәдәни мирас объектларының (федераль әһәмияттәге аерым мәдәни мирас объектлары исемлегенә кертелгән федераль әһәмияттәге мәдәни мирас объектларыннан тыш), региональ әһәмияттәге мәдәни мирас объектларының мәгълүмат язулары һәм билгеләре проектларын карау һәм килештерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 4 нче кушымта

## Дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту һәм гаризаны һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен тулы нигезләр

| № | Идентификатор | Мөрәҗәгать итүче тапшыра торган документлар төрләренең шифрын ачу, төркемнән документлар саны |
|---|---|---|
| *Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләре:* | | |
| 1. | 1А-4А | мәдәни мирас объектындагы мәгълүмат язуы проекты эчтәлегенең Россия Федерациясе халыклары мәдәни мирас объектларының (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләренең) бердәм дәүләт реестрындагы белешмәләргә туры килмәве; |
| 2. | 1А-4А | проектның Россия Федерациясе халыклары мәдәни мирас объектларындагы (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләрендәге) мәгълүмат язулары һәм билгеләр эчтәлегенә һәм мондый урнаштыру гамәлгә ашырыла торган мәгълүмат язулары һәм билгеләрен урнаштыру һәм аларның эчтәлеге проектлары составына карата Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе халыклары мәдәни мирас объектларына (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләренә) мәгълүмат язулары һәм билгеләр урнаштыру кагыйдәләрен, әлеге мәгълүмати язуларының һәм билгеләренең эчтәлеген, шулай ук мондый урнаштыру гамәлгә ашырыла торган мәгълүмат язулары һәм билгеләрен урнаштыру һәм аларның эчтәлеге проектлары составына таләпләрне раслау турында» 2019 елның 10 сентябрендәге 1178 номерлы карары белән расланган таләпләргә туры килмәве; |
| 3. | 1А-4А | Татарстан Республикасы Мәдәни мирас объектларын саклау комитеты тарафыннан расланган мәдәни мирас объектының сак предметына туры килмәве |

| *Гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр* | | |
|---|---|---|
| 1. | 1А-4А | дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза рәвешендә мәҗбүри кырларны дөрес тутырмау (төгәл түгел, дөрес түгел яисә тулысынча тутырмау) |
| 2. | 1А-4А | тапшырылган документларның дәүләт хезмәте күрсәтүне сорап мөрәҗәгать итү вакытына көчен югалтуы (шәхесне таныклый торган документ, мөрәҗәгать итүче вәкиленең вәкаләтләрен таныклый торган документ, – дәүләт хезмәте күрсәтүне сорап әлеге зат мөрәҗәгать иткән очракта) |
| 3. | 1А-4А | мөрәҗәгать итүче тарафыннан кәгазьдә тапшырылган документларда Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган чистартылган һәм текстны төзәткән урыннар булуы |
| 4. | 1А-4А | электрон рәвештә тапшырылган документларда дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларда булган мәгълүматны һәм белешмәләрне тулы күләмендә файдалану мөмкинлеген бирми торган бозык урыннар булуы |
| 5. | 1А-4А | электрон рәвештәге гариза һәм башка документлар электрон имза белән «Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы федераль закон таләпләрен бозып имзаланган |

Федераль әһәмияттәге мәдәни мирас объектларының (федераль әһәмияттәге аерым мәдәни мирас объектлары исемлегенә кертелгән федераль әһәмияттәге мәдәни мирас объектларыннан тыш), региональ әһәмияттәге мәдәни мирас объектларының мәгълүмат язулары һәм билгеләре проектларын карау һәм килештерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 5 нче кушымта

Татарстан Республикасы Мәдәни мирас объектларын саклау комитеты рәисенә

______________________________________
фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта)

кемнән: ______________________________
(физик затлар өчен: Ф.И.А. (атасының исеме – булган очракта), адресы яисә фактик яшәү урыны, адресы (почта һәм (яисә) электрон)

______________________________________
юридик затлар өчен: оешма исеме, адресы (почта һәм (яисә) электрон) (элемтә өчен телефон номеры (номерлары)

Гариза

Мәдәни мирас объектының мәгълүмат язуы һәм билгесе проектын каравыгыз һәм килештерүегез турында сорыйм ______________________________________
(«федераль» яисә «региональ» категориясен күрсәтергә)

әһәмияттәге ____________________________________________________________
(мәдәни мирас объекты исеме)

урнашкан адресы: ________________________________________________
(мәдәни мирас объектының урнашу урыны)

________________________________________________________________________

Җавапны түбәндәгечә җибәрүегезне сорыйм (вариантларның берсен сайларга):

Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең республика порталына;

әлеге адрес буенча: __________________________________________________

электрон почта адресына: _________________________________________.

Кушымталар:

1. Мәдәни мирас объектының мәгълүмат язуы һәм билгесе проекты;
2. Башка документлар ______________________________________________________.

________________________________________________________________________
Вазыйфа имза Ф.И.А. (ата исеме - булган очракта)

«___» __________ 20__ ел.
М.У. (булган очракта)

Федераль әһәмияттәге мәдәни мирас объектларының (федераль әһәмияттәге аерым мәдәни мирас объектлары исемлегенә кертелгән федераль әһәмияттәге мәдәни мирас объектларыннан тыш), региональ әһәмияттәге мәдәни мирас объектларының мәгълүмат язулары һәм билгеләре проектларын карау һәм килештерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 6 нчы кушымта

Мәдәни мирас объектының мәгълүмат язуы һәм билгесе проектын килештерү турында карар формасы

(Комитетның рәсми бланкында рәсмиләштерелә)

Кемгә: ________________________________

(физик затлар өчен: Ф.И.А. (атасының исеме – булган очракта), адресы яисә фактик яшәү урыны, адресы (почта һәм (яисә) электрон)

_______________________________________

юридик затлар өчен: оешма атамасы, адресы (почта һәм (яки) электрон)

Мәдәни мирас объектының мәгълүмат язуы һәм билгесе проектын килештерү турында

Хөрмәтле _____________________________________!

(мөрәҗәгать итүченең исеме һәм атасының исеме (соңгысы – булган очракта))

Федераль әһәмияттәге мәдәни мирас объектының (федераль әһәмияттәге аерым мәдәни мирас объектлары исемлегенә кертелгән федераль әһәмияттәге мәдәни мирас объектыннан тыш), региональ әһәмияттәге мәдәни мирас объектының мәгълүмат язуы һәм билгесе проектын карау һәм килештерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү турында Сезнең гаризага җавап итеп, әлеге мәдәни мирас объекты буенча:

______________________________________________________________________________

_______________________________________________ әһәмияттәге _____________

(категориясе: «федераль» яисә «региональ»)

______________________________________________________________________________

(мәдәни мирас объекты исеме)

урнашкан адресы: ________________________________________________

(мәдәни мирас объектының урнашу урыны)

______________________________________________________________________________

Татарстан Республикасы Мәдәни мирас объектларын саклау комитеты (алга таба – Комитет) түбәндәгеләрне хәбәр итә.

Тәкъдим ителгән проект «Россия Федерациясе халыклары мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләре) турында» 2002 елның 25 июнендәге

73-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә билгеләнә торган тәртиптә расланган таләпләргә туры килә.

Бәян ителгәннәрне исәпкә алып, Комитет күрсәтелгән мәдәни мирас объектының мәгълүмат язуы проектын килештерә.

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2019 елның 10 сентябрендәге 1178 номерлы карары белән расланган Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләренә) мәгълүмат язулары һәм билгеләре урнаштыру кагыйдәләре нигезендә әзерләнгән пластинаны (пластиналарны) килештерелгән проект нигезендә урнаштыру ул килештерелгән көннән алып 180 календарь көннән дә соңга калмыйча оештырылырга тиеш.

Мәгълүмат язуын урнаштыру эшләре тәмамланганнан соң 30 календарь көнгә кадәр башкарылган эшләр турында, мәгълүмат язуын урнаштыру эшләрен башкару датасын күрсәтеп, һәм эш башланганчы, аларны башкару барышында һәм мәгълүмат язуын урнаштыру тәмамланганнан соң мәдәни мирас объектының төсле фотофиксациясен теркәп, Комитетка хәбәр ителергә тиеш.

Өстәмә мәгълүмат (булган очракта тутырыла).

Кушымта: расланган проект______________ биттә.

Татарстан Республикасы Мәдәни мирас объектларын саклау комитеты рәисе

____________________/___________________________________

Имза фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта)

«___» __________ 20__ел.

М.У. (булган очракта)

Федераль әһәмияттәге мәдәни мирас объектларының (федераль әһәмияттәге аерым мәдәни мирас объектлары исемлегенә кертелгән федераль әһәмияттәге мәдәни мирас объектларыннан тыш), региональ әһәмияттәге мәдәни мирас объектларының мәгълүмат язулары һәм билгеләре проектларын карау һәм килештерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 7 нче кушымта

Мәдәни мирас объектының мәгълүмат язуы һәм билгесе проектын килештерүдән баш тарту турында карар формасы
(Комитетның рәсми бланкында рәсмиләштерелә)

Кемгә: ___________________________________
(физик затлар өчен: Ф.И.А. (атасының исеме – булган очракта), адресы яисә фактик яшәү урыны, адресы (почта һәм (яисә) электрон)

___________________________________________
юридик затлар өчен: оешма атамасы, адресы (почта һәм (яки) электрон)

Хөрмәтле _________________________________________!
(мөрәҗәгать итүченең исеме һәм атасының исеме (соңгысы – булган очракта))

Федераль әһәмияттәге мәдәни мирас объектының (федераль әһәмияттәге аерым мәдәни мирас объектлары исемлегенә кертелгән федераль әһәмияттәге мәдәни мирас объектыннан тыш), региональ әһәмияттәге мәдәни мирас объектының мәгълүмат язуы һәм билгесе проектын карау һәм килештерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү турында Сезнең гаризага җавап итеп, әлеге мәдәни мирас объекты буенча:

________________________________________________________________________________
__________________________________________________ әһәмияттәге ______________
(категориясе: «федераль» яисә «региональ»)

________________________________________________________________________________
(мәдәни мирас объекты исеме)

урнашкан адресы: _____________________________________________________
(мәдәни мирас объектының урнашу урыны)

________________________________________________________________________________

Татарстан Республикасы Мәдәни мирас объектларын саклау комитеты (алга таба – Комитет) түбәндәгеләрне хәбәр итә.

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2019 елның 10 сентябрендәге 1178 номерлы карары белән Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләренә) мәгълүмат язударын һәм билгеләрен урнаштыру кагыйдәләре; Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларында (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләрендә) мәгълүмат язулары һәм билгеләренең эчтәлеге; мондый урнаштыру гамәлгә ашырыла торган мәгълүмат язуларын һәм билгеләрен

урнаштыру проектлары составына һәм эчтәлегенә карата таләпләр билгеләнгән.

Мәдәни мирас объектының мәгълүмат язуы һәм билгесе проектын карау барышында түбәндәге туры килмәү очрагы ачыкланды *(кирәклесен сайларга)*:

| | |
|---|---|
| | мәдәни мирас объектындагы мәгълүмат язуы проекты эчтәлегенең Россия Федерациясе халыклары мәдәни мирас объектларының (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләренең) бердәм дәүләт реестрындагы белешмәләргә туры килмәве; |
| | проектның Россия Федерациясе халыклары мәдәни мирас объектларындагы (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләрендәге) мәгълүмат язулары һәм билгеләр эчтәлегенә һәм мондый урнаштыру гамәлгә ашырыла торган мәгълүмат язулары һәм билгеләрен урнаштыру һәм аларның эчтәлеге проектлары составына карата Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе халыклары мәдәни мирас объектларына (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләренә) мәгълүмат язулары һәм билгеләр урнаштыру кагыйдәләрен, әлеге мәгълүмати язуларының һәм билгеләренең эчтәлеген, шулай ук мондый урнаштыру гамәлгә ашырыла торган мәгълүмат язулары һәм билгеләрен урнаштыру һәм аларның эчтәлеге проектлары составына таләпләрне раслау турында» 2019 елның 10 сентябрендәге 1178 номерлы карары белән расланган таләпләргә туры килмәве; |
| | Татарстан Республикасы Мәдәни мирас объектларын саклау комитеты тарафыннан расланган мәдәни мирас объектының сак предметына туры килмәве |

Бәян ителгәннәрне исәпкә алып, Комитет объектның мәгълүмат язуы һәм билгесенең тәкъдим ителгән проектын килештерүдән баш тарта
______________________________________ әһәмияттәге ____________
(категориясе: «федераль» яисә «региональ»)
____________________________________________________________
(мәдәни мирас объекты исеме)
урнашкан адресы: ________________________________________
(мәдәни мирас объектының урнашу урыны)
____________________________________________________________.

Сез әлеге мәдәни мирас объектының мәгълүмат язуы һәм билгесе проектын эшләп бетерергә һәм карау өчен кабат тапшырырга хокуклы.

Татарстан Республикасы Мәдәни мирас объектларын саклау комитеты рәисе
_________________/____________________________
Имза фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта)

«___»__________20__ел.
М.У. (булган очракта)